Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге составына керүче
Яншык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

01 апрель 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 01 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Сез гражданнар Җыенының 19.10.2023 ел 1нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ризамы:
1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегеннән түбәндәге пунктларны алып атырга:
- торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );
- авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу );
- авыл җирлеге территориясен җәйге вакытта чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
-торак пункт территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 62 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 44 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 44 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Яншык авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегеннән түбәндәге пунктларны алып атырга:

   - торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

 - торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );

   - авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу );
   - авыл җирлеге территориясен җәйге вакытта чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

2.2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
-торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы,23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Динмөхәмәтов